Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы торак пунктында үткән гражданнар җыенын нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2020 елның 2 ноябре №1

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе нигезендә 2020 елның 2 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча үткәрелгән гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде: «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына көндезге бүлекләргә йөреп укучы студентлардан һәм 1 группа инвалидлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Солтан авылында Комсомол, Р.Шәрәфеев, Бакча урамнарындагы вак таш җәелгән юлларны төзекләндерүгә (вакланган таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эш барышы өчен түләү);

- кышкы чорда авыл җирлегенә керүче торак пунктлардагы юлларны карап торуга:

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган, җыенда катнашучылар исемлегенә 216 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 137 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 137 кеше тавыш бирде;

"ЮК" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

Гражданнар җыенында куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешеедән (уку йортларына көндезге бүлекләргә йөреп укучы студентлардан һәм 1 группа инвалидлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара

салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Солтан авылында Комсомол, Р.Шәрәфеев, Бакча урамнарындагы вак таш җәелгән юлларны төзекләндерүгә (вакланган таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эш барышы өчен түләү);

- кышкы чорда авыл җирлегенә керүче торак пунктлардагы юлларны карап торуга».

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы торак пунктында үткән гражданнар җыенын әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р.Р.Сөнгатуллин

Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000725
ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Р 06-601/02